КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1252

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1326 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1326 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 1 июнь, 509 нчы; 2022 ел, 28 июль, 725 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

икенче абзацта «13 610 482,04626 мең сум» сүзләрен «15 259 954,83579 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «402 459,5 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә федераль бюджеттан кергән акча һәм 94 404,04 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» сүзләрен «400 553,296 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә федераль бюджеттан кергән акча һәм 93 956,908 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «10 421 438,0 мең сум күләмендә бюджет кредитлары рәвешендә федераль бюджеттан кергән» сүзләрен «14 283 061,0 мең сум күләмендә бюджет кредитлары рәвешендә федераль бюджеттан кергән» сүзләренә алмаштырырга;

унбишенче абзацта «5 253 405,91374 мең сум» сүзләрен «589 064,45814 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «59 137 586,08527 мең сум» сүзләрен «65 981 987,08320 мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасын, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Яр Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән программаны, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программаны, «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән программаны, «Төбәк, муниципальара һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын үстерүгә ярдәм күрсәтү» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлегенә юнәлдерелгән программаны, Инфраструктура проектларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән программаны, «Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә субсидия исәбеннән юл эшләрен башкару чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән программаны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин